РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Евлаштау, ул.Ш. Бариева, 23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Явлаштау авылы, Ш. Бариев урамы, 23 нче йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.04.2025

КАРАР
№ 13

Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 28.04.2018 №10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.04.2025 елгы №228 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 30.04.2018 елгы №10 карарына (Советның 09.11.2020 №10, 18.10.2022 №18, 19.12.2022 №26, 19.08.2024 №14, 13.11.2024 №26 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 15389 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 30.04.2018 елгы №10 карарына ( Советның 20.11.2018 №26, 19.12.2022 №26, 19.08.2024 №14 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. 2.3 пунктында «1,0717 акчалата бүләкләү күләмендә» сүзләрен «1,29 акчалата бүләкләү күләмендә » сүзләренә алштырырга

2.2. 3.5.4 нче пунктның икенче җөмләсендә «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алыштырырга»;

2.3. 6.1 пунктының 2 подпунктында «4,65 айлык акчалата бүләкләү» сүзләрен «15,48 айлык акчалата бүләкләү» сүзләренә алыштырырга;

2.4. 7.1 пунктының 5 подпунктында «18 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 маеннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан гамәлгә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Явлаштау авыл
җирлеге Башлыгы Р.Х.Нуриев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Явлаштау авыл җирлеге
Советының 25.04.2025 №13 карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге Башлыгы | 21091 |
| Депутатлар | 15389 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 15389 |